КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 25 май г.Казань № 638

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен раслау турында» 2012 ел, 14 февраль, 118 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен раслау турында» 2012 ел, 14 февраль, 118 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның беренче абзацында «гомуми файдаланудагы төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары» сүзләрен «гомуми файдаланудагы төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары (алга таба - гомуми файдаланудагы төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары)» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Фондның бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзү тәртибе турында» 2008 ел, 28 март, 206 нчы карары белән расланган Чираттагы финанс елына һәм план чорына

Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзү тәртибе турындагы нигезләмә  һәм әлеге Тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

икенче абзацта «Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте фонды» сүзләрен «Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасында:

алтынчы һәм җиденче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәре белән ел әйләнәсе элемтәсе булмаган авыл торак пунктларына кадәр каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) проектлау, төзү, реконструкцияләү, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре исәбеннән автомобиль бензинына, турыдан-туры куылган бензинга, дизель ягулыгына, дизель һәм (яисә) карбюратор (инжектор) двигательләре өчен мотор майларына кертелергә тиешле Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре, шулай ук транспорт салымы, шул исәптән җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата күрсәтелгән юл эшчәнлегенә субсидияләр рәвешендә, исәбеннән төзелә торган Фондның бюджет ассигнованиеләре күләменең кимендә 5 проценты күләмендә капиталь ремонт һәм ремонт;

гомуми файдаланудагы төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларын төзү (реконструкцияләү), капиталь ремонтлау һәм ремонтлау (яисә) төзү, юлларны капиталь ремонтлау һәм ремонтлау эшләрен гамәлгә ашырган очракта, машина юллары  белән бер дәрәҗәдә булган трамвай юлларын (контакт челтәрләреннән һәм йөк ярдәмче станцияләреннән тыш) реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау, шулай ук җирле бюджетларга трамвай юлларын реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга һәм ремонтлауга субсидияләр рәвешендә (контакт челтәрләреннән һәм йөк ярдәмче станцияләреннән тыш),  гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү (реконструкцияләү), капиталь ремонтлау һәм ремонтлау эшләре башкаруга һәм (яисә) юлларны төзү (реконструкцияләү), капиталь ремонтлау һәм ремонтлауга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирү;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гомуми файдаланудагы төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларына карата башка чараларны гамәлгә ашыру;»;

«г» пунктчада «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Юл  фонды» сүзләрен «Фонд» сүзенә алмаштырырга;

«а» пунктчасында «Татарстан Республикасы Юл  фонды» сүзләрен «Фонд» сүзенә алмаштырырга;

7 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

8 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү идарәсе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин